ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

14 ноябрь, 2025 ел. Яңа поселогы №2

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең Иске Гәрдәле авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Совет карары белән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Әҗмәкәй авыл җирлегенең 25.10.2019 ел, № 51/3 «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Әҗмәкәй авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында «нигезләмәне раслау хакында»,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 26 ноябрь көнне 2025 елның сәгать 18.00 Иске Гәрдәле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2026 елда Иске Гәрдәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1500 (бер мең биш йөз сум) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II төркем инвалидлар һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, Әфганстанда, Чечняда сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, чернобыльчеләр-ЧАЭСТА авария ликвидаторлары, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар, күп балалы гаиләләр һәм студентлар өчен бер тапкыр түләүне киметергә риза буласызмы? 750 (җиде йөз илле сум) сум күләмендә әлеге категория гражданнар өчен билгеләргәһәм РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взнослар түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдереләчәк:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юллар төзү эшләрен башкару, юлларны ремонтлау, вак таш һәм асфальт валчыклары сатып алу, махсус техника хезмәтләре күрсәтү);

2) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (технологик тоташтыру, электр материаллары сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру);

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Гәрдәле авылы парклары территориясен төзекләндерү, кече архитектура формаларын, спорт элементларын сатып алу һәм урнаштыру);

4) коеларны төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

5) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

6) торак пункт территориясен төзекләндерү.

"КАРШЫ" ӘЙЕ.

3. Халык җыенын беренче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Иске Гәрдәле авылы, Үзәк урамы, 46А йорт адресы буенча үткәрергә.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә.

5. Әлеге карарны мәгълүмәт стендларында бастырып чыгагырга.

6. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар аның игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Әҗмәкәй авыл җирлеге Башлыгы Г.Т.Хөсәинова